МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

25.12.2018 г.Казань № 1146

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 24 гыйнварендә теркәлде, № 5405

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Инвалид бала өчен сатып алынган товар барлыгын тикшерү актын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 26 декабрендәге 737 номерлы боерыгы белән расланган Инвалид бала өчен сатып алынган товар барлыгын тикшерү актын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Инвалид бала өчен сатып алынган товар барлыгын тикшерү актын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 26 декабрендәге 737 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 26 сентябрендәге 906 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Инвалид бала өчен сатып алынган товар барлыгын тикшерү актын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушытада бирелә торган үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 25.12.2018 № 1146 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Инвалид бала өчен сатып алынган товар барлыгын тикшерү актын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 26 декабрендәге 737 номерлы боерыгы белән расланган Инвалид бала өчен сатып алынган товар барлыгын тикшерү актын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә 2.4 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте гаризаны әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар белән теркәгән көннән башлап 5 календарь көненнән соңга калмыйча күрсәтелә.»;

3 бүлектә:

3.3 пунктта 3.3.3 пунктчаның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгән көндә башкарыла.»;

3.4 пунктның 3.4.1 пунктчасындагы алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны Идарәдә (бүлектә) теркәгән даталан башлап ике календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.»;

3.4 пунктның 3.4.2 пунктчасындагы бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән датадан соң биш календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.»;

3.6 пунктның 3.6.1 пунктчасындагы алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар техник хатаны төзәтү турында гариза теркәлгән датадан башлап бер календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.»;

3.6 пунктның 3.6.2 пунктчасындагы дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура тикшерү актында техник хатаны төзәтү турында гариза теркәлгән датадан башлап бер календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.»;

2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Инвалид бала өчен сатып алынган товарның булуын тикшерү актын бирү буенча дәүләт хезмәте

күрсәтүнең административ
регламентына 2 нче кушымта

**ИНВАЛИД БАЛА ӨЧЕН САТЫП АЛЫНГАН ТОВАРНЫҢ БУЛУЫН ТИКШЕРҮ АКТЫН БИРҮ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕ КҮРСӘТКӘНДӘ ГАМӘЛЛӘРНЕҢ ЭЗЛЕКЛЕЛЕГЕ БУЕНЧА БЛОК-СХЕМА**



товар булуын тикшерү нәтиҗәләрен форма буенча актта терки;
тикшерү актына имза сала - акт төзелгән көнне (гаризаны теркәгән датадан башлап 5 календарь көненнән соңга калмыйча)

Инвалид бала өчен сатып алынган товар булуын тикшерү турында төзелгән һәм бирелгән акт

Мөрәҗәгать итүчедән техник хатаны төзәтү турында гариза килгән очракта, Идарә (бүлек) белгече тикшерү актын төзәтә - 1 календарь көне

Төзәтелгән тикшерү акты

Идарә (бүлек) җитәкчесе төзәтелгән тикшерү актын таныклый һәм имзалый - 1 календарь көне

Таныкланган һәм имзаланган тикшерү акты

Идарә (бүлек) белгече мөрәҗәгать итүчегә төзәтелгән тикшерү актын җиҗәрә/тапшыра - 1 календарь көне

Инвалид бала өчен сатып алынган товар булуын тикшерү турында төзәтелгән һәм бирелгән акт».